Бүгенге санда:

Президент программасы эштә: спорт мәйданчыклары арта. 3 бит



1931 елның 9 июленнән бирле чыга

# Дуслык

Дружба

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

Чәршәмбе 29 июль 2015 ел

№ 54 (10583)

**30 июльгә һава торышы:** аязучан болытлы һава, яңгыр, үзгәрүчән юнәлешле җил, 8-9 м/с; температура көндез +27°С, төнлә +18°С

ХӘБӘРЛӘРЕГЕЗНЕ КӨТӘБЕЗ

Телефоннар: 2-36-13, 2-36-20.

## Абзац-информ

### ӘЗЕРЛЕК ТИКШЕРЕЛӘ

Кичә, 28 июльдә районның мәгариф һәм мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренең яңа уку елына әзерлеген тикшерү башланды. Район комиссиясе 2015-16 уку елына әзерлекне 31 июльгә кадәр караса, 3 августтан республика комиссиясе эшләячәк.

### ПРОБЛЕМАЛЫ УРАМ – ҮЗӘКТӘ

ЮХИДИ бүлегеннән хәбәр итүләренчә, шәһәрдәге иң күп кагыйдә бозулар теркәлгән участокларның берсе – Кооператив урамы икән. Көн саен юл инспекторлары шәһәр үзәгендә 30дан артык кагыйдә бозуны ачыклап, машина йөртүчеләргә карата административ беркетмәләр төзиләр.

### КОМБАЙННАР ТӘРТИПТӘ БУЛЫРГА ТИЕШ

Дүшәмбедән республикада “Комбайн-2015” операциясе старт алды. Гостехнадзорның Нурлат бүлегеннән хәбәр итүләренчә, 14 августка кадәр дәвам итәчәк операция уракка җәлеп ителгән кыр корабларын куркынычсыз эксплуатацияләүне, хокук бозулар белән көрәшне көчәйтүне максат итә. Бу чорда комбайннарның һәм алар белән идарә итүчеләрнең тиешле документларының тәртиптә булуына аерым игътибар биреләчәк.

### КОМПЬЮТЕР СЕРЛӘРЕНӘ ӨЙРӘНӘЛӘР

Бу көннәрдә Нурлат шәһәре халкының мәшгульлеге үзәге аша 20 пенсионер “Перспектива” укыту үзәгендә компьютер грамоталыгы нигезләренә өйрәнә. Пенсионерлар компьютерда эшләү күнекмәләре алу белән беррәттән, Интернет челтәрендә эшләргә һәм Дәүләт хезмәтләре порталыннан файдаланырга да өйрәнәләр.

# Көнне төнгә ялгап эшләр чак



НИКОЛАЙ КАЗАКОВ ИКЕНЧЕ ЕЛ РӘТТӘН УРАККА ТҮБӘН КАМАДА АВТОМЕХАНИК ҺӨНӘРЕ АЛУЧЫ СТУДЕНТ ЕГЕТ ВИТАЛИЙ ГЕРАСИМОВ БЕЛӘН ЧЫГА.

Лилия Мөбарәкшина фотосы

**Район игенчеләре бу атнада коры көннәрнең һәр минутын максималь файдаланып эшли. Дүшәмбе көнне районда игеннәр 1687 гектарда җыеп алынды.**

Бу көнне “Южная” агрофирмасы җәмгыятенең 7 комбайны Иске Чаллы ягындагы 170 гектарлы уҗым бодае басуында игеннәрне җыеп алды да икенче – 350ләп гектарлы басуга китәргә җыенды. Ике атналар чамасы берөзлексез койган яңгырлардан соң әле генә иркенләп эшләргә мөмкинлек булды бит, шуңа да биредә озакка тоткарланмадылар. Хуҗалыкның иң тәҗрибәле һәм алдынгы комбайнчыларыннан булган Николай Казаков белән дә быелгы урак хакында сүз алышырга гына өлгерәбез.

– Яңгырларның озакка сузылуы файдага түгел инде, – ди ул. – Әнә, басулар ничек ямь-яшел булып китте. Ә бу ашлыкның сыйфатына да, эш темпына да йогынты ясый – комбайнның җайланмаларын әледән-әле чистартып торырга туры килә.

Николай Казаковның комбайнчы стажы дистәләгән еллар белән исәпләнә. Кайчандыр “Нива” комбайнын иярләгән, соңрак “Дон”га күчеп утырган, хәзер инде 4 елдан артыграк “АКРОС”та эшли. Басулардан рекордлы уңыш җыйган елларны да яхшы хәтерли, берничә ел рәттән табигатьнең авыл хуҗалыгын коры көннәр белән сынавын да борчылып кабул итә. Әнә, язгы өметләр быел да акланмады. Әмма, ничек кенә булмасын, комбайнчы алдына басудагы ашлыкны вакытында һәм тиешенчә җыеп алу бурыч итеп куела.

*(Ахыры 5нче биттә)*

АКТУАЛЬ

# Мәктәп формасы бердәм булачак

**Агымдагы уку елыннан районның барлык мәктәп укучылары яңа формаларга күчәчәк. 5 еллап мәҗбүри саналган “шотландка” итәкләр һәм тасмалы костюмнар “модадан чыгачак”.**

Тик Ульян фабрикасында тегелгән мәктәп формаларының бәясе кайбер әти-әниләрне канәгатьләндереп бетерми.

– Беренче сыйныфка баручы улыма яңа мәктәп формасы комплекты 4500 сумга төште, – ди бер әни. – Комплектка пинжәк, жилет һәм чалбар керә. Әле сыйфаты яхшы булса, сүз дә әйтмәс идең, материалы да синтетика бит. Башка җитештерүчеләрдән түмәрләп алганда, комплектның бәясе 3400 сум гына. Район мәгариф бүлеге җитәкчелегенә бердәм форма керткәндә, Татарстан җитештерүчеләре белән эшләүне кирәк тапмадымы икән? Әле бит баланы мәктәпкә озатканда спорт костюмы, аяк киемнәре, сумка, башка әйберләр дә күп кирәк. Кара исәп белән генә дә 10 мең сумнарга төшә...

– ТР Мәгариф һәм фән министрлыгында безгә республика җитештерүчеләре белән эшләргә тәкъдим ителгән иде, – ди район мәгариф бүлеге җитәкчесе Линар Маняпов. –Аларның да бәяләре арзан түгел. Ульян җитештерүчеләренең товарлары ГОСТ таләпләренә туры килә, яңа мәктәп формалары классик стильдә һәм бәяләре чамалы булганга, аларны сайладык. Моннан тыш, әлеге фабрика аз керемле гаиләләргә ташламалар тәкъдим итә. Апрель аенда ата-аналар фабрика тәкъдим иткән формалар һәм прайс-листлар белән таныштылар, канәгатьсезлек белдермәделәр. Әлеге фабрика шәһәрнең 4нче урта мәктәбе һәм гимназия белән күптәннән эшли инде.

Мәктәп формалары совет мәктәпләрендә 1948 елдан бирле гамәлдә. Шул еллар эчендә аның стиле шактый үзгәргән. Үзгәртеп кору елларында аннан баш тартучылар да булды. Тик бу дисциплинаны шактый аксатты, диләр белгечләр. Еш кына мәктәп формасы аркасында гаиләләрдә низаглар да чыга торган булган әле.

– Укучыларның формасы җайлы һәм сыйфатлы материаллардан эшләнергә тиеш, – ди Линар Нурисламович. – Бердәм стиль, төс, фасонны районның барлык мәктәп директорлары белән бергә сайладык. Бердәм мәктәп формасы балаларны уку процессына активрак тарта һәм өлгерешне үстерә. Районда яңа формага күчү этаплап алып барылачак. Ульян фабрикасыныкын кыйммәтсенгән әти-әниләр шундый ук фасондагы формаларны башка җитештерүчеләрдән сатып ала алалар. Быел кертеләчәк формалар мода артыннан куу түгел, ә дресс-код ул.

Зилия ӘКСАНОВА

### САН

**Ульян фабрикасы тәкъдим иткән бердәм мәктәп формасы комплекты бер укучыга 4-7 мең сумнарга төшәчәк.**

ИНФРАСТРУКТУРА

# Авылны мәйданчыклар да бәхетле итә

**Узган атнада Нурлат районы тагы ике универсаль спорт мәйданчыгына баеды: Иске Чаллы авылында – спорт-уен, ә Яңа Иглайда катнаш спорт мәйданчыклары үз ишекләрен ачты.**



Автор фотосы

ЯҢА МӘЙДАНЧЫКТАГЫ БЕРЕНЧЕ МАТЧНЫ РАЙОН БАШЛЫГЫ БАШЛАП ҖИБӘРДЕ

Бүгенге көндә Казан Россиянең спорт башкаласы санала. Гомумән, Татарстанда башкалабызда гына түгел, ә район-авылларда да спорт белән шөгыльләнү өчен һәвәскәрләргә дә, профессионалларга да барлык мөмкинлекләр тудырылган, һәм бу юнәлештә эш дәвам итә. Районыбызда бер-бер артлы универсаль мәйданчыклар ачылып тору да нәкъ шуны раслый. Әлбәттә инде, әлеге корылмаларның яшь спортчылар тәрбияләүдә дә, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауда да әһәмиятләре бик зур.

Мәсәлән, Иске Чаллы авылы районкүләм, шулай ук Нурлат данын республикада да лаеклы яклаучы яшь спортчыларны күп тәрбияләп тора. Быел ГТО нормалары тапшыру буенча районда да яхшы күрсәткеч Иске Чаллы укучыларында. Шуңа да мондый мәйданчыкны күптән көткән идек, ди мәктәп директоры Владимир Белогубов.

– Ишегалдында ук корылганлыктан, бу гүзәл мәйданчык мәктәбебезнең йөзе дә булып торачак әле. Шөкер, спорт сөюче яшьләребез күп, һәм спорт мәйданчыгы алар өчен бер дигән бүләк булды, – диде Владимир Ильич.

Әлбәттә, спорт корылмасына иң сөенгәннәре укучылар булды. “Мәктәбебездә чаңгы спорты белән шөгыльләнүчеләр күп. Хәзер исә без сезонга менә шул мәйданчыкта җиен дә ныклап әзерләнә алабыз, җиңел атлетика белән шөгыльләнү өчен дә бер дигән”, – ди Иске Чаллы мәктәбе укучысы Марина Нестерова. Мәйданчыкны ачу тантанасына яшь гаиләләр дә күпләп җыелган иде. Мәсәлән, Ольга Домаркас нәни Лизасы белән кайбер тагannарны сынап та караганнар инде.

– Балалар өчен төрле тагannар, атынгычлар булуы бик әйбәт. Җитәкчеләребезнең авыл халкын кайгыртуыннан бик тә күңел булды, – ди яшь ана.

Яңа Иглайда исә яшь футбол сөючеләрне дә бәхет басты: биредә спорт-уен мәйданчыгыннан тыш, ясалма өслекле футбол кыры да бар. Бу көнне биредә беренче матчлар да уздырылды.

– Бу мәйданчыкта уйнавы әйтеп бетергесез рәхәт, җайлы, – ди шатлыктан балкыган Айзат Рәхмәтуллин. – Мондый шартларда шөгыльләнгәч, без районда да беренче урыннарны алырга тиеш булабыз инде хәзер. Утлар да куелса, төнлә дә кайтып кермәбездер, мөгаен: бигрәк рәхәт бит!

Биредә дә авылның яше-карты спорт корылмалары ачылуны зур вакыйга дип кабул итә. Әнә, Йосыф ага Фәйзуллин ак күлмәкләрдән бәйрәмчә киенеп иртән-иртүк бирегә юл алган.

– Бу мәйданчык минем бакча башында гына. Бакчада эшләгәндә, биредән балаларның шатлыклы чыр-чуын ишетеп сөенгәнемне белсәгез, күңелләр тула, – ди Йосыф ага. – Безнең заманда мондый нәрсәләр юк иде бит, балаларыбыз бик бәхетле. Хәер, республика хөкүмәтенең, район җитәкчелегенең безне шулай кайгыртуыннан авылыбыз белән бәхетле без.

Ике авылдагы вакыйгада да катнашкан район башлыгы Равил Кузюров исә мәйданчыкларның бик вакытлы ачылуын ассызыклап узды.

– Төзүчеләребезгә рәхмәт, ике корылманы да вакытында, ягъни каникулларның кызган чорына җиткерә алдылар. Димәк, балаларыбызның буш вакытларында шөгыльләнергә, яңа уку елына көч тупларга бер дигән мөмкинлекләре булачак, – диде ул.

Равил Әфраимовичның ике авыл халкына да җиткергән яңалыклары иске чаллылылар һәм иглайлылар күңеленә янә сары май булып ятты.

**САН**

**2013-2014 елларда гына да Татарстанда 322 спорт мәйданчыгы төзелгән. 2015 елда 10 спорт объекты файдалануга тапшырылды, шуларның 5се – бассейн белән. Әлеге объектлар федераль программалар һәм республика бюджеты хисабына корылалар.**

– Авылларыбызны кайгыртуны алга таба да дәвам итәбез. Шөкер, республикада күп төрле программалар уңышлы тормышка ашырылып килә. Менә бүген ачкан мәйданчыклар да Президент программасы буенча сафка бастырылды. Ә киләсе елга Иске Чаллыда мәдәният йортын, Яңа Иглайда мәктәпне капиталь ремонтларга ниятләп торабыз, – диде ул, һәм халык бу матур хәбәрне сөенеп, алкышлар белән кабул итте.

Районда моңа кадәр дә берничә спорт мәйданчыгы корган “Стройгранд” җәмгыятенең гомуми мәсьәләләр буенча директоры Илнар Кәлимуллин биредәге тренажерларны чыдамлы һәм куркынычсыз дип билгеләп үтте.

– Барлык инвентарь да сыйфатлы һәм куркынычсыз, озак еллар хезмәт итәргә сәләтле материалдан ясалган. Биредә нәни балалар да курыкмыйча уйный ала, чөнки нинди дә булса җәрәхәт алу ихтималы бөтенләй юк дияргә мөмкин, – ди ул.

Район башлыгы Равил Кузюровның мәйданчыкларны ачу тантанасында әйткән сүзләре исә әлеге гаҗәеп корылмаларның кадерен бермәбер арттыргандыр, мөгаен.

– Мондый мәйданчыклар булу – сезнең өчен зур бәхет. Шуңа балалар, яшьләр, өлкәннәр дә әлеге спорт корылмаларын дөрес итеп файдаланыр, авылларда спорт белән шөгыльләнү, сәламәт яшәү рәвешенә тартылу тагы да активлашыр дип ышанам, – диде ул.

Илназ МӨБАРӘКШИН

# Балык хәлен күзләреннән белеп була

КУЛЛАНУЧЫЛАРГА

**Кышкы чордагы кебек үк, җәен дә базар киштәләре ит һәм балык ризыкларына мул була. Тик әлеге ашамлыкларны курыкмыйча сатып алучылар бармы икән? Чөнки сыйфатсыз товар сатып алу ихтималы да юк түгел бит.**

“Әле генә елгадан тотып кайттык”, “Төнлә генә тоткан идек әле” – җәйге чорда үз машиналарыннан балыкларын шул рәвешле мактап торучыларны еш очратырга була. Матур, өстәвенә, тыпырчынып та яткан балык авызга сулар китерә. Әмма товарның “кыяфәте” сыйфат өчен дә борчылмаска була, дигән сүз түгел әле. Билгеле булганча, балык судагы барлык токсик матдәләрне үзенә туплый, зарарлы пычрак суда яшәүче балыкка авыр металл тозлары да җыела. Ә аны нинди елга яки күлдән тотканнары билгесез, аның суы йогышлы авырулар белән зарарланган булса? Бу сорауга балыкчының җавап бирүе икеле. Шуңа да сатып алучыларның ветеринария службалары тарафыннан тикшерелгән балык продукциясенә өстенлек бирүе гаҗәп түгел.

– Ит, балык кебек продуктларны 0...+6 градуста сакларга кирәк, – ди Нурлат районы дәүләт ветеринария берләшмәсе каршындагы ветсанинспекция лабораториясе мөдире Светлана Кузнецова. Аның әйтүенчә, универсаль базарда сатылучы барлык балык та сәнәгый производстводагы санала һәм сертификатлары, накладнойлар, 2нче формадагы ветеринар таныклык кебек тиешле документлар белән кайта икән.

– Базардагы лабораториядә без кертү контроле ясыйбыз: балыкның сыйфатлы икәнлеген раслаучы документларны тикшерәбез. Әгәр шик туа калса, пробага һәм анализга сайлап алабыз. Безнең бурыч киштәләргә бары тик сыйфатлы продукцияне генә үткәрүдән гыйбарәт, – ди лаборатория мөдире.

Балык – тиз бозылучан продукт, шуңа да аны даими тикшереп торырга кирәк. Әнә, базардагы лаборантлар да һәр өч сәгать саен карау уздыралар. Моннан тыш, барлык продукция дә дозиметрик контроль үтә.

– Базарда барлык балык та үзебез илнеке дияргә була – Камчатка, Сахалин, Приморье, Мурманскида, шулай ук Ульянда тотылган. Нигездә, эшмәкәрләр аларны Самарадагы түмәрле базадан алып кайталар. Ассортимент та тулы, – диде Светлана Кузнецова һәм балык продукциясен саклау нечкәлекләрен дә әйтеп үтте. – Балык бары тик ябык биналарда гына сатылырга тиеш. Ә базарда барлык шартлар да тудырылган, сәнәгый суыткычлар бар, алар тиешле булган –20 градуслы температураны саклап тора. Сату нокталарында туңдыру, әзер продукция өчен витриналар куелган.



Автор фотосы

КИҢ ДИАПАЗОНЛЫ ДОЗИМЕТР ЯРДӘМЕНДӘ СВЕТЛАНА КУЗНЕЦОВА ПРОДУКЦИЯНЕҢ РАДИАЦИОН КУРКЫНЫЧЛЫЛЫК ИХТИМАЛЫН АЧЫКЛЫЙ.

Балыкны саклау шартлары – мөһим момент. Баксаң, дөрес сакламаганда һәм транспортировкаламаганда балык сәламәтлеккә зыян салырга мөмкин икән.

– Балыкта паразитлар бар, алар туңдырганда һәм термик эшкәрткәндә юкка чыга. Шуңа да аны дөрес әзерләү дә мөһим әле. Әлеге авырулар балыкны кимендә 20 минут кыздырганда һәм пешергәндә бетә. Алабуга, кәрәкә, чуртан һәм төче сулыкларда яшәүче башка балыклар куркыныч патоген һәм суалчаннар корбанына әвереләләр. Андый суалчанны күрергә һәм юк итәргә була әле, ә менә микроскопигы күренми, һәм ул кеше өчен куркыныч тудырырга мөмкин, – ди Светлана Кузнецова. Бу исә “Ни өчен балыкны теләсә каян сатып алырга ярамый?” – дигән сорауга җавап та инде.

Сирень СӘМӘРХАНОВА

**ИГЪТИБАР!**

**Тазә балыкның тәне тыгыз, тәңкәсе ялтыравык, лайласы үтә күренмәле, йөзгечләре бөтен, күзләре кабарынкы була. Күптән тотылган балык ябышкак, нык исле, тонык, эчкә баткан күзле була.**

КӨН КАДАГЫНДА

# Ярыкка–ямаулык...

**11 июльдә Пермь шәһәрендә бишкатлы йорт ишелеп, ике кеше үлде. 12 июльдә Омск янындагы ВДВ гаскәрләре укыту үзәге казармасы бинасы ишелеп, 24 кеше һәлак булды.**

Бу хәбәрләр Нурлатта Карл Маркс урамы, 1 нче йортта яшәүче Сания Сәлманованы янә чаң сугарга мәҗбүр итте.

Аларның 1996 елда төзелгән йорт язмышы әллә ничегрәк булып чыга: нигезе түбән, подвалында су тора, йортына чыгар хәл юк–базарга керүче машиналар агымы туктамый. Әмма барыннан да яманы–йортның стеналарында ярыклар пәйда була. 1998 елда бу уңайдан Дәүләт торак инспекциясе вәкилләре катнашында йортка тикшерү дә үткәрәләр. Төзүчеләр–"53нче СМУ" җитәкчелегенә төзәтергә тиешле кимчелекләр күрсәтелгән предписание әле дә Сания апаның проблемага кагылышлы кәгазьләр төргәгендә саклана. Пунктлап язылган җитешсезлекләр шактый. Ул чакта йортка килеп, нидер эшләүче булганын гына хәтерләми хуҗабикә. Ә менә проблеманы тирәнәйтерлек хәлләр озак көттермиләр: халык күп йөри торган юл өстендә урнашкан йортны эшмәкәрләр үз итә башлый. 2011 елдан башлап, бүгенге көнгә кадәр бу йортның беренче катында 6 офис җиһазланган. Сания апа әйтүенчә, хәзер инде 7нчесен ачарга теләүче ханым күршеләреннән рөхсәт сорап имза җыя башлаган.

–Куймыйбыз, дигән идек, бездән сорагандай гына итәләр, барыбер үзләренекен эшлиләр инде, – ди Сания Сәлманова.–Моңарчы миннән сорап торучы да булмады, фатирларны ишә башлагач кына белә идек яңа күршеләр килүен.

Ә "күршеләр" дигәннәре йортка шактый тынычсызлык китерәләр. Фатирны офис иткәнче, стеналарны да ватарга, ишекләрне дә үзенчә җайлап урнаштырырга туры килә бит. Коне–тоне кирпеч ватулардан йорт кына түгел, Сания апа һәм анда яшәүчеләр дә дер селкенеп тора. Балкон өстендәге, тәрәзә кырыендагы ярыклар да киңәя, обой ертыла...

– Кем әйтә ала без дә пермьлеләр хәлендә калмабыз дип? – ди ветеран. – Мин Ленинград камалышларыннан, Моздок мәхшәрләреннән котылып та кирпеч астында калып үләргә һич теләмим.

Сания Бариевнаның бу проблемасы турында узган ел бер язган идек инде. Ул вакытта район архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегеннән, Чистай торак инспекциясеннән вәкилләр катнашында комиссия килеп, ярыкка маячок ябыштырып киткәннәр. Ноябрь аенда аны карап, ситуациягә бәя биргәннәр: ярыкның зураюы күзәтелмәгән.

– Йортта урнашкан офисларда несущий стеналарны вату булмады, – ди шәһәр архитекторы Наталья Крайнова.– Бары адвокатлар конторасында гына ишек уйдылар, әмма алар тулы проект ясап, стенага өстәмә ныгытма конструкцияләр куйдылар. Ярыклар йорт төзелеше вакытында җибәрелгән җитешсезлекләргә бәйле, дип уйлыйбыз. Йорт утырганда хасил булган алар. Әлбәттә, торак йортны торак булмаган фондка күчерү әйбәт күренеш түгел, күршеләрдән рөхсәт алу–аның төп шарты. Күрәсең, кемнәрдер ниндидер юллар белән аны урап үтәргә маташа булып чыга. Ә бу йорттан соңгы вакытта безгә гариза белән мөрәҗәгать иткән кеше юк.

Бүлмә планировкасын үзгәртү йортның торышына тәэсир итми дисәләр дә, бөтенләй үк йогынтысыз булмыйдыр. Бигрәк тә яшәеш башыннан ук төзелештә җитешсезлекләр җибәрелгән мондый йортта. Мәгълүмат чыганакларыннан күренгәнчә, Пермьдәге фаҗигане бер сәбәбен дә шушы офислар, кибетләр урнашуга бәйләп карыйлар бит һәм аны тыюны да таләп итмәкчеләр. Мәскәү шәһәре Думасы да бу уңайдан Торак кодексына төзәтмә әзерли. Анда нигездә 15 елдан артык хезмәт иткән иске йортларда кибетләр урнашуны тыю турында сүз бара. Караганда өлкәсе хакиме дә шул хакта сүз кузгата. Нигезләре бер: 1 катта фатирлар сәүдә яки офиска үзгәртү өчен исәпләнмәгән, бу гомуми конструкцияне боза. Димәк, проблема бер Сания Сәлманова һәм аның күршеләрен генә уйга салмаган. Аерма шунда гына: кемнәрдер уйлый, ә андый йортларда яшәүчеләр ут эчендә. Ыржайган ярыкларны битараф җаваплар белән генә ямап булмас шул...

Сәкинә **ХӘЙРУЛЛИНА**

*Редакциядән: Сания Сәлманова проблемасы белән шәһәр прокуратурасына да чыккан. Ә сез бу уңайдан нинди фикердә? Әйдәгез, сөйләшүне дәвам итик!*

# Көнне төнгә ялгап эшләр чак

*(Ахыры. Башы 1нче биттә)*

Басулардагы яшел үлән исә агрономнарда да борчу тудыра. Бу яктан узган елда да урып-җыюда десикация – игеннәрне тигез өлгертү өчен махсус препаратлар белән эшкәртү ысулыннан файдаланганнар иде, быел да шундый ниятләре юк түгел. Бу ысулны нигездә орлыкка алыначак басуларда кулланачаклар. Ә коры елларда, әлбәттә инде, сыйфатлы һәм яңа сортлы культуралар шактый ярдәм бирә. Әнә, быел "Памяти Кунакбаева" сортлы арышлары матур уңыш белән сөендерде. Андый өметле басулары исә әле тагы да бар.

Озакка сузылган яңгырлар тулаем урып-җыюның барышына да йогынты ясады. Уҗым культураларын урып-җыярга өлгерми калдылар, инде сабан ашлыгы, борчак өлгереп җитте. Соңгысы 600ләп гектарда хуҗалыкта, аның бер өлешен сенажга ала башладылар инде. Гомумән, уракта мәшгуль булган 10 комбайн экипажына да эш җитәрлек, бу һәркайсына 800ләп гектар мәйданда эш туры килә бит.

– Комбайнчылар сыната торган түгел безнең, өлгерләр. Бу яктан борчылмыйбыз, үз эшләрен җиренә җиткереп башкара торганнардан, – ди хуҗалык җитәкчесе Әдһәм Гарифуллин.

Берүк вакытта терлекчелек комплексында бөртекне яньчелдереп әзерләү бара. Игеннәрне җыеп алу белән басуга – салам әзерләүчеләр бригадасы килеп эшкә керешә. Быел кырлардагы саламны тулысы белән терлекләргә әзерләп калуны бурыч итәләр. Авыллар янәшәсендәге басулардан саламны төргәкләп комплекска ташуны оештырсалар, ерактагы басуларда өемгә куеп калдырачаклар. Шул ук вакытта авыллар халкына җәмәгать маллары өчен дә өлеш чыгармакчылар. Саламчылар бригадасы эшне тәмамлау белән бушап калган басуларда инде туфрак эшкәртүгә дә керешкәннәр. Анысы да көн кадагында – авыл хуҗалыгында барына да җитешим дисәң, эшләрне һәрчак әнә шулай комплекслы алып бару кирәк. Ә чәчүлек мәйданнары буенча районда икенче урында торган "Южная"да эшне оештыра да, көнне төнгә ялгап башкара да беләләр.

Лилия **МӨБАРӘКШИНА**

**28 июльгә район хуҗалыкларында урып-җыюның барышы, барлык мәйданнарга карата процентларда**




# Элиталы солдатлар алар

ВАТАНГА ХЕЗМӘТ

**Узган елгы чакырылышта гына да Нурлатның 6 егете элиталы гаскәрләрдә хезмәт иткән.**

– Теләсә кайсы частьның җитәкчелеге Нурлат егетләрен яратып кабул итә, – ди шәһәр хәрби комиссары Заһир Абдуллин әле генә армия сафларыннан кайтып төшкән Торнәс авылы егетләре, бертуган Евгений һәм Андрей Титовларны каршы алганда. – Армиядә безнең егетләрнең дәрәҗәсе бар. Нурлат егетләре армиягә зур әзерлек белән китәләр. Әтиәниләре, район җитәкчелеге, хәрби комиссариат исеменә килгән Рәхмәт хатлары да шул хакта сөйли.

Бертуганнар Евгений белән Андрей да узган ел язгы чакырылышта армия сафларына киткәндә, элиталы гаскәрләргә эләгү турында хыялланган булган икән.

– Сәламәтлегебез яхшы, беребез вуз тәмамлаган югары белемле, икенчебез Аграр университеттан академик ял алды, – диләр егетләр. Һәм аларның хыяллары үзләре көткәннән дә уңышлырак тормышка да ашып куя. Район җитәкчелеге, республика хәрби комиссары Сергей Погодинның хәер-фатихасы белән алар Владивостоктагы 30926 хәрби частьның диңгез пехотасы бригадасына эләгәләр. Бертуганнар 7 тәүлек буе 9 мең километр араны узуның да уңай якларын тапканнар: ил буенча сәяхәт кылу булды ул, диләр.

– Армиягә барышлый дөнья да күрдек, – ди Андрей. – Ә 1 ел хәрби хезмәт безгә бик зур тормыш мәктәбе булды. Диңгез пехотасында дисәләр дә, 10 тапкыр парашюттан сикерергә дә туры килде, 1 айга Австралиягә сәяхәт кылдык: корабль озата бардык. 20 километр ераклыкка марш-бросок йөгерүләрне, яшь сугышчы мәктәбен узуларны без беркайчан да онытмаячакбыз.

Егетләр Җиңүнең 70 еллыгына багышланган хәрби парадта катнашып, махсус медальгә дә ия булганнар әле. Моннан тыш, Россия армиясенең иң масштаблы "Восток-2014" стратегик команда-штаб өйрәнүләрендә дә катнашканнар.

Сер түгел, моннан 5-10 ел элек егетләр армиягә бик ашкынып тормый иде. Ә бүген яшьләрнең дөньяга карашы үзгәрде, яхшы эшкә урнашырга, тормышта үз урыннарын табарга телиләр. Ә моңа армия хезмәтеннән башка ирешеп булмый диярлек, шуңа да алар Ватан алдындагы изге бурычларын үтәргә ашыгалар.

– Армиядә шартлар бик әйбәт, – диләр Титовлар. – Ашату ягыннан да, спорт һәм тәрбия юнәлешендә дә зарланырлык урын юк. Командирлар бик көчле, акыллы. Алга таба үсәргә ярдәм итәргә ашкынып торалар. Хәтта мәктәпне тәмамлый алмаган егетләргә алга таба укырга, тормышта үз урыннарын табарга ярдәм итәргә дә әзерләр.

Ә Титовлар хәзер гражданлык тормышына җайлашалар. Егетләр ирешелгәннәрдә тукталып кала торганнардан түгел: Евгенийның вузны тәмамлыйсы бар, ә Андрей эшкә урнашу мәшәкатьләре белән яши.

Зилия **ӘКСАНОВА**




ЕГЕТЛӘРНЕ ХӘРБИ КОМИССАР КАРШЫ АЛДЫ

## КОТКАРУЧЫЛАР БӘЙГЕГӘ ӘЗЕРЛӘНӘ

"ТатРИТЭКнефть" ТППсы цехлары арасында күптән түгел үткән коткаручылар конкурсын олы бәйгегә әзерлек дип атарга була. Аларның "РИТЭК" ААҖ предприятиеләре арасындагы олы бәйгесе Яр Чаллыда сентябрь аенда узачак.

## ЧЕМПИОНАТКА – КОЛЛЕКТИВ БЕЛӘН

1 августта "ТатРИТЭКнефть" ТППсының 50 хезмәткәре Казанга, су спорты төрләре буенча Дөнья чемпионатын карарга барачак. Профсоюз линиясе буенча оештырыла торган әлеге чарага бүгеннән билетлар алынган, транспорт хәл ителгән, хезмәткәрләр дә сәфәргә бик теләп ризалашкан.

Сәкинә **НУРУЛЛИНА**

## ЯРЫШ УЗДЫ

20 июльдә Халыкара шахмат көне билгеләп үтелде.

Әлеге дата уңаеннан район шахматчылары арасында традицион турнир уздырылды. Бәйгедә барлыгы уноч кеше көч сынашты. Нәтиҗәдә, I урынны Сергей Анисимов алды, II-III урыннарны Михаил Безруков белән Анатолий Сидоров бүлештеләр. Мондый бәйге Нурлатта унберенче тапкыр уздырылды.

Илназ **МӨБАРӘКШИН**

## ТӨРЛЕ. РЕКЛАМА

СОЦИАЛЬ ПРОЕКТЛАР

# Матур да, файдалы да

**2014 елда “РИТЭК” ААҖнең социаль һәм мәдәни проектлар конкурсында нибары бер мәктәпкәчә учреждение катнашкан булса, быел 3 балалар бакчасы заявка биргән инде.**

Заманча уен комплекслары белән җиһазланган балалар бакчасы сабыйлар гына түгел, аларның әти-әниләре өчен дә зур шатлык. Әнә, “Тирмәкәй” бакчасына йөрүче балаларның да шундый сөенечләре бар хәзер. Берничә көн ремонттан соң, дүшәмбе иртәсенә биредәге балалар мәйданчыгы танымаслык итеп үзгәргән иде: бирегә яңа заманча җиһазлар куйганнар. Эш шунда, узган ел бакча мөдире Татьяна Фадеева “РИТЭК” ААҖнең социаль һәм мәдәни проектлар конкурсында катнашып, грантка лаек булды.

Грант акчаларына балалар спорт мәйданчыгына заманча җиһазлар кайтарттылар: өскә үрмәләү җайланмасы, баскетбол боҗрасы дә бар анда. Барлык конструкцияләр дә сертификатлаштырылган материалдан, алар мәктәпкәчә балалар учреждениеләре өчен махсус ясала. Мисал өчен, өскә үрмәләү җайланмасының каркасы тимер беркетмәле агачтан һәм пластиктан эшләнгән. Баксаң, бу мөмкинлекләр бакчага йөрүче балалар өчен генә дә түгел икән.

– Катнашкан проектыбыз “Семейный спортивный клуб “Ладушки” дип аталды, – ди Татьяна Фадеева. – Без “Шәфкатьлелек” номинациясендә җиңдек. Сатып алган җайланмаларыбыз мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен дә исәпләнгән. Шуңа да балалар бакчасының эш режимы кысаларында ул бездәге сабыйлар карамагында булса, ял көннәрендә бирегә мөмкинлекләре чикләнгән балалар үз әти-әниләре белән килә ала.

Бакча мөдирен соцпроектлар конкурсында катнашуга әлеге учреждениенең яңа уку елына әзерлеген тикшергән комиссия әгъзалары этәрә. Мөдир, сынап караргамы икән, анда барлык Россиядән меңләгән шундый учреждение катнаша бит, дип озак уйлап тормый, документларын җыя да Казанга озата. Тырышлык бушка китми. Бүген балалар бакчасы коллективы янә конкурста катнаша. Бу юлы энергия саклау юнәлешендә – “ТРда мәгариф өлкәсендә 50 инновацион идея” дигән бәйге ул.

– Монысында “Якты бакча” проекты белән катнашабыз. Әгәр җиңә алсак, грантны үзебез теләгәнчә файдалана алабыз, – ди Татьяна Фадеева.

Гомумән, “РИТЭК”ның социаль һәм мәдәни проектлар конкурсында катнашу – нурлатлылар өчен гадәти хәл. Проектлар да төрле: шәһәрне, чишмәләрне төзекләндерү һәм яшелләндерүгә, сквер, стадионны реконструкцияләүгә, балалар мәйданчыклары төзүгә юнәлдерелгәннәре бар... Мәсәлән, Картлар һәм инвалидлар интернат-йорты 2014 елда “Могҗизалар планетасы” проектында катнашып, сенсорлы бүлмә җиһазлау өчен грант откан иде, хәзер аны монтажлау эшләре бара. Интернат директоры Евгений Савинов әйтүенчә, бу җайланма биредә яшәүчеләрнең сәламәтлеген ныгытуга булышачак икән. Быелгы конкурста катнашу өчен заявкалар кабул итү дә башланды. Бу көннәрдә Нурлат комиссиясе 44 заявкадан 22 проектны сайлап алды, аларны якын көннәрдә Казанга җибәрәчәкләр. Проектта катнашучы шәһәрнең әлеге 3 мәктәпкәчә учреждениесе дә ота калса, тагы 3 балалар бакчасы үз базаларын яхшыртачак, дигән сүз.



СОЦПРОЕКТЛАР КОНКУРСЫ “ТИРМӘКӘЙ”ГӘ ЗАМАНЧА СПОРТ МӘЙДАНЧЫГЫ КОРЫРГА ЯРДӘМ ИТКӘН

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**

МӘГАРИФ

### 700дән АРТЫК БАЛА УКЫРГА КЕРӘ

Нурлат районында 700дән артык бала беренче сыйныфка укырга барачак. Яңа уку елына район мәктәпләрендә барлыгы 50ләп сыйныф комплектланган. Шәһәр мәктәпләре 2-3әр комплект сыйныф җыйган.

### БАКЧАЛАРДА КОМПЛЕКТЛАУ БАРА

Районның мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә июнь башыннан балаларны бакчаларга комплектлау эше башланды. Аның беренче агымында электрон чират аша барлыгы 363 балага урын бирелгән. Бу эшнең икенче агымы 17-27 августта узачак.

### РЕМОНТНЫ ВАКЫТЫНДА ТӨГӘЛЛӘГӘННӘР

27 июльдә агымдагы ремонт эшләреннән соң, районның 30лап балалар бакчасы да үз ишекләрен ачты. Һәр бакчада да азык блоклары, территорияләр тәртипкә китерелгән, буяу-агарту эшләре башкарылган.

**Зилия ӘКСАНОВА**


СДАЮТСЯ

*гараж с подъемником, инструментами, ул. Михеева, 14. Т. 8-937-529-32-68.

*квартира посуточно. Т. 8-927-456-05-69.

*в аренду помещение (мкр. Яшлек), помещение (около ТЦ «Шифа»), гаражи в центре. Т. 8-927-248-48-04.

*квартира в центре. Цена договорная. Т. 8-937-773-80-73.

*1-комнатная квартира в районе сахарного завода. Т. 8-927-497-81-94.

СНИМУ

*квартиру в Казани. Т. 8-919-691-86-84.

*-Профнастил*
*- Сайдинг*
*- Утеплитель*
*- Доборные элементы.*
*Доставка.*
*Выезд на замер - бесплатно.*
*Кредит АО «ОТП Банк».*
*Т.: 8-927-470-29-39,*
*8-987-409-27-06.*
***Универсальный рынок,***
***м-н «Инструмент-град».***

**ООО «МИР КРОВЛИ»**
**реализует**
ПРОФНАСТИЛ С9, С20, С21, НС44, Н60, Н75 (оцинкованный и окрашенный), длина до 12 метров, металлочерепицу, металлосайдинг, металлоштакетник, профильную трубу, гладкий лист, доборные элементы. Утеплитель. Парогидроизоляция. Поликарбонат. Теплицы.
Доставка по городу бесплатно.
Гарантия на всю продукцию.
**Т.: 8-927-826-53-32, 8-937-273-87-15, 8(84235) 2-75-35, 2-75-25. E-mail: mir-krovli73@bk.ru**

**31 июля и 1 августа**
(2 дня) в здании типографии фирма **«РОЛЕ СОЛЕ»** проводит выставку-продажу *мужских и женских курток, плащей, ветровок и женской джинсовой одежды (брюки, бриджи, юбки),* г. Санкт-Петербург.
**Ждем вас с 9.00 до 18.00.**

**3 августа с 14 до 15 ч.**
**в Ц. р. аптеке №94 ул. Гагарина, 10**
**Слуховые аппараты**
**Аналоговые, цифровые, сверхмощные:**
**от 7000 руб. до 15000 руб.**
**При сдаче старого аппарата скидка на новый до 2000 руб.! Тел. 89225036315**
Имеются противопоказания. Необходима консультация специалиста.
ИП Коробейникова Е.М. Св № - 305183220300021

**Дети - наше будущее**
* Прием детского специалиста в области офтальмологии
* Исследование зрения на компьютерном оборудовании
* Решение проблем при косоглазии, амблиопии, близорукости у детей
**Салон «ДОКТОР ОПТИКА»**
**г. Нурлат, ул. Советская, 120,**
**т.: 2-17-88, 8-927-427-79-27,**
**ул. Гиматдинова, 81,**
**т.: 2-91-99, 8-937-610-69-30,**
Лиц. №16-01-000675 от 13.12.2007г., выд. Фед.службой по надзору в сфере здравоохранения и соц.развития.
Имеются противопоказания. Необходима консультация специалиста.

**1 августа** в поликлинике ЦРБ ведут прием специалисты МДЦ г.Казань по следующим направлениям:
эндокринология
неврология
кардиология
сосудистая хирургия (с аппаратурой).
Врачи проведут исследования на высокотехнологичном оборудовании.
Т. 8-917-269-54-27.
Имеются противопоказания. Необходима консультация специалиста.

**«УДАЧА»**
**Набирается группа в Сочи на сентябрь**
**Т. 8-927-417-17-10.**

ПАМЯТНИКИ –
мрамор, гранит.
Фото на граните.
Доставка по городу бесплатно.
Ул. Ленинградская, 14.
**8-987-420-05-97.**

Только **1 и 2 августа** на территории школы №4 (Нурлат, ул. Дружбы, 68) пройдет ярмарка школьной одежды от Ульяновской фабрики *«ЭЛЕГАНТ»* по ценам 2014 года.
**1 августа - с 8 до 19 ч.**
**2 августа - с 8 до 16 ч.**

**С 29 июля по 9 августа 2015 г.**
**РАСПРОДАЖА**
*колготок и чулочно-носочных изделий в магазине «Калейдоскоп» (продуктовый рынок). Цены ниже оптовых. Подробности по тел. 8-927-424-85-61.*
ИП Садыкова З.Ф.

**МАГАЗИН «СПОРТТОВАРЫ»**
- ТРЕНАЖЕРЫ
- САМОКАТЫ
- ВЕЛОСИПЕДЫ
- РОЛИКИ
- МЯЧИ
- ФИТНЕС
- КОНЬКИ
- БОКС
И ДР. СПОРТИВНЫЙ ИНВЕНТАРЬ.
Мини-рынок (мясокомбинат).

**ЖАЛЮЗИ.**
Все виды.
Замер и установка бесплатно.
**8-927-672-01-17.**

**ДОСТАВКА ПЕРЕГНОЙ, ЧЕРНОЗЕМ, ГРУНТ, ПЕСОК, ПГС, ДРОВА КОЛОТЫЕ, ЧУРБАКАМИ И ДЕФЕКАТ 8-937-280-94-84.**

**В магазине «МУЖСКАЯ ОДЕЖДА»**
**(центр, ул. Советская, 86)**
**СЕЗОННАЯ РАСПРОДАЖА, СКИДКИ до 40%***
***Скидки предоставляются с 22.07.15 по 01.08.15 г.**
**ИП Мавлютова Ф.С.**

**В КОНСУЛЬТАТИВНО-ДИАГНОСТИЧЕСКОМ ЦЕНТРЕ «САУЛЫК», Г. НУРЛАТ, УЛ. ЖЕМЧУЖНАЯ, 25, ВЕДУТ ПРИЕМ СПЕЦИАЛИСТЫ ИЗ Г. КАЗАНИ ПО СЛЕДУЮЩИМ НАПРАВЛЕНИЯМ:**

1 августа 2015 года
1. Терапия, кардиология, ревматология.
2. Педиатрия-кардиология.
3. Сосудистия хирургия, новый революционный метод при варикозной болезни вен, не требующий госпитализации и наркоза. Помощь при сосудистых звездочках.
4. Врачи проведут на высокотехнологичном оборудовании исследования сердца, эхокардиоскопию с ЦДК (цветное допплеровское картирование).

2 августа 2015 года
1. Гинекология, репродуктология. Решение проблем при бесплодии. Ведение беременности.
2. Диетология.
3. Урология. Помощь при эректильной дисфункции, ЗППП, мужском бесплодии, хр.простатите, аденоме предстательной железы.
4. Врачи проведут исследования органов малого таза, плода на 1,2 и 3 триместрах.

8 августа 2015 года
1. Гастроэнтерология.
2. Онкогинекология-эндокринология, специализации по менопаузе.
3. Терапия, кардиология, ревматология.
4. Педиатрия-кардиология.
5. Неврология.
6. Врачи проведут на высокотехнологичном оборудовании исследования сердца, эхокардиоскопию с ЦДК (цветное допплеровское картирование).

9 августа 2015 года
1. Отоларингология.
2. Эндокринология.
3. Аллергология. Иммунология. Решение проблем бронхиальной астмы, аллергических дерматитов, кожных заболеваний
4. Пульманология.

КДЦ предлагает услуги по ДМС через Нурлатский филиал СК «Чулпан».
Результаты обследования принимаются в БМСЭ.
Справки и предварительная запись по т.: 2-43-03, 8-927-037-40-01.
ООО «Услуга» КДЦ «Саулык». Лиц. ЛО-16-01-001191 от 30.09.2010г. ОГРН 1021605358103.
**Имеются противопоказания. Необходима консультация специалиста**

Реклама